**Муса Җәлил**

**Яшь ана**

Авыл яна... Шәфәкъ нуры булып
Уйный күктә янгын шәүләсе.
Күмерләнгән өйнең тупсасында
Аунап ята ана гәүдәсе.

Алты айлык бала елый-елый
Капшый анын сулган күкрәген!
Ятып суыра, туктап карап тора,
Үксеп уа аннан күзләрен.

Палач үзе кача көнбатышка,
Өстерәлә ватык көймәсе.
Куа аны арттан, ядрә булып,
Ана каны, бала күз яше.

Күрше кызы Сәрвәр базда иде,
Иштеп чыкты бала тавышын.
Кинәт, куркып, сүзсез катып калды,
Үлгән килеш күреп танышын.

Ул баланы алды кочагына,
Яшен сөртте, үпте, юатты.
Алып кайтты, җылы сөт эчерде,
Кулларына алып уйнатты.

Ул сикертте аны тезләрендә,
Ана дәрте анда кабынды.
Бала көлде, аннан: «Әннә!» — диеп,
Күкрәгенә анын сарылды.

Сәрвәр әле бары унҗидедә,
Тормыш аңа яңа башлана.
Ул елмая ана назы белән,
Ана бәхете белән шатлана.

Сез күрерсез, шундый матур итеп
Ул баланы карар, үстерер.
Тәрәзәдән һәр кич яшь ананың
Дәртле бишек җыры иштелер.

Күңлем оча минем канатланып,
Аның җырын тыңлап узганда.
Рәхмәт сиңа, илем! Шундый йөрәк
Биргән өчен безнең кызларга.

**1943 ел**